# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

24 октябрь, 2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45- ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 22 октябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2019 елның 24 октябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2019 елның, узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? » соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

б) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм төзекләндерү.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 113 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 79, бу 69,9 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 79 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен- дөрес дип таныргa.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

б) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм төзекләндерү.» - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы Е.Н. Алексеева